Республика Татарстан
СОВЕТ ВЕРХНЕСИМЕТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422068, Республика Татарстан,
с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422068, Татарстан Республикасы,
Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
17.12.2025

КАРАР
№ 26

Саба муниципаль районы Югары Симет авыл
җирлеге Советының 27.04.2018 ел, №10
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Югары Симет авыл җирлеге җирле
үзидарә органнары депутатларының, сайланулы
вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренең
хезмәт өчен түләү шартлары турында
Нигезләмә»карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025 ел, №994 "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 № 182" үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының , контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.1. Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» 27.04.2018 ел, № 10 карарына (советның 09.11.2020 ел, №12, 20.10.2022 ел, №14 ,19.12.2022ел, № 19 , 13.11.2024 ел № 26, 25.04.2025 ел № 11 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 16 928 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2026 елның 1 январеннән гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.
3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.
5. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/simet адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

Югары Симет авыл
җирлеге башлыгы                                        И.Р.Әхмадуллин

Кушымта №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге советының 2025 елның 17 декабреннән № 26 карарына

**Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге башлыгы, депутатлар, Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы вазыйфаи затларына акчалата бүләк күләме**

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 25 401 |
| Депутатлар | 16 928 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 16 928 |